**АКТАНЫШСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423740,село Актаныш, проспект Ленина,дом 58 ,тел.3-15-99.

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКТАНЫШ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 58 нче йорт. Тел.3-15-99

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№ 6**

**КАРАР**
**«20» май 2019г**

Транспорт чаралары хәрәкәте өчен юлны ябу турында

Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән бәйле рәвештә, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү максатларында, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Актаныш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районының Актаныш авыл башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Актаныш авылы, Ленин проспекты адресы буенча урнашкан 1 һәм 2 номерлы күпфатирлы торак йортлар арасындагы ишегалдына транспорт чаралары хәрәкәте өчен юлны ябарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Актаныш авыл җирлеге»бүлегендә урнаштырырга.

3.Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Актаныш авыл
Башкарма комитет җитәкчесе И. Ш. Шәрәпов